КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 26 апрель г.Казань № 279

Татарстан Республикасында төбәк яки муниципальара әһәмиятле автомобиль юлларында, җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында түләүле парковкалардан файдаланган өчен түләү күләмен исәпләү методикасын раслау һәм аның максималь күләмен билгеләү турында

«Россия Федерациясендә юл хәрәкәтен оештыру турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 29 декабрендәге 443-ФЗ номерлы Федераль законның 6 статьясындагы 1 өлешенең 7 пункты һәм «Татарстан Республикасында юл хәрәкәтен оештыру өлкәсендә кайбер мәсьәләләрне җайга салу турында» 2018 елның 20 декабрендәге 103-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 4 статьясындагы 1 өлешенең 5 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Татарстан Республикасында төбәк яки муниципальара әһәмиятле автомобиль юлларында, җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында түләүле парковкалардан файдаланган өчен түләү күләмен исәпләү методикасын расларга.

2. Татарстан Республикасында төбәк яки муниципальара әһәмиятле автомобиль юлларында, җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында түләүле парковкалардан файдаланган өчен максималь түләү күләмен бер сәгатькә 140,0 сум күләмендә билгеләргә.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин